ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

23 март 2021 ел № 51

Нурлат муниципаль районы Советының 2016 елның 7 сентябрендәге 166 номерлы «Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибе турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Нурлат муниципаль районы Советының 2016 елның 7 сентябрендәге 166 номерлы карарына кушымта белән расланган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

Тәртипнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлеге түләүсез бирелү хокукына ия гражданнар (алга таба - гражданнар) индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык, яшелчәчелек буенча үз хокукларын бер мәртәбә гамәлгә ашырырга мөмкин.

32.1 статьяның 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Җир кодексы, Нурлат муниципаль районы составына керүче авыл җирлеге чикләрендә яшәүче гражданнар, үз ризалыгы булган очракта, Нурлат шәһәре чикләрендә җир кишәрлеге алу хокукына ия.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин